ГЛАВА
Кучуковского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

14.11.2019

Тубән Көчек
авылы

№ 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Варкләд-Бодья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башлыгы, к а р а р б и р д е:

1.2019 елның 27 ноябрендә Варкләд-Бодья авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 13 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Көчек авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Варкләд-Бодья авылында Яшләр урамына вак таш түшәү.

2. Варкләд-Бодья авылының Яр буе урамында су челтәрен алыштыру.

3. Варкләд-Бодья авылы суэтем башнясын санитар саклау йөзеннән койма белән әйләндереп алу.

4. Варкләд-Бодья авылы зират коймасын тоту.

5. Варкләд-Бодья авылы янгын сүндерү машинасының штаттан тыш хезмәткәренә хезмәт хакы түләү.

6. Варкләд-Бодья авылы юлларын кыш көне кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Р.Ә.НУРМӨХӘМӘТОВ